**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№11 9 сентябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Ташкичү

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт

турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү

турында

Федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге советын **карар итте**:

1. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2017 елның 07ноябрендэге 12 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 12 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 3нче өлешне өстәргә:

« Гражданин һәм муниципаль хезмәткәр, якын туганнары яисә кардәшләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы булганда, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре (ата-анасы, хатыны, балалары, абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, хатыны-иренең ата-анасы, ир-белән хатынның балалары, балаларның ирләре һәм хатыннары) булганда, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый.

2. 13 статьяда түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:

«2.1. Муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында җитәкче булганда, үз вазыйфасын биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый".

3.  Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru  веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән  һәм Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Валеев.